**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ УЛЬЯНОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Центральная ул., 44 дом, Ульяновка село, 423115 тел./факс+7(84396) 2-33-16/2-33-17; email: Ul.Cmn2@tatar.ru Үзәк урамы, 44 йорты, Ульяновка авылы, 423115

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

**№ 130** **«28» октябрь 2024 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Ульяновка авыл җирлеге Советының**
**«Җир салымы турында»**
**2020 елның 27 октябрендәге № 10**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 27 октябрендәге № 10 карарына (Советның 2023 елның 29 сентябрендәге 99 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «2) торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир

кишәрлекләренә карата 0,3%, әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш".».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга

3. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Ульяновка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе С.З. Шәмсетдинов